СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

____________________ с. Сарманово №________________

**2015 елның 10 декабрендәге 20 номерлы карар**

**«2016 елга Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
бюджеты турында»**

Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

Статья 1

2016 елга Сарман муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Сарман муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 710 209,2 мең сум итеп;

2) Сарман муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 710 209,2 мең сум күләмендә;

3) Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум күләмендә.

2016 елга Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 2

1. 2017 елның 1 гыйнварына Сарман муниципаль районының эчке бурычының югары чиге 0,00 сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча бурычның югары чиге 0,00 сум күләмендә.

2. Сарман муниципаль районының 2016 елга муниципаль бурычының иң чик күләмен 0,00 сум күләмендә билгеләргә.

Статья 3

Сарман муниципаль районы бюджетында 2016 елга Сарман муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2016 елга Сарман муниципаль районы бюджет системасы

бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 5

1. Сарман муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 6

2016 елга Сарман муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2016 елга бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Сарман муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Сарман муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Сарман муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Сарман муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2016 елга 18 157,3 мең сум күләмендә расларга.

Статья 7

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр, аларны финанс белән тәэмин итү Сарман муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслауның үз керемнәре һәм чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган субвенцияләр, бюджетара субсидияләр, Сарман муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар Сарман муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан расланган тәртиптә бирелә.

Статья 8

1. Җирлекләр бюджетларыннан Сарман муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга түбәндәге килешүләр нигезендә исәпкә алырга:

- 2016 елга торак фондына капиталь ремонт буенча 9 126 мең сум күләмендә, әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүленеп;

- 2016 елга җирлекләрдә яшәүчеләрне ял итүне оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча 49 209,1 мең сум күләмендә, әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә бүленеп;

- 2016 елга җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына бухгалтерлык хезмәте күрсәтү буенча 2 482,0 мең сум күләмендә, әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә бүленеп.

2. 2016 елда Сарман муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертларны әлеге статьяда каралган җирлекләр бюджетларыннан күчерү ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара трансфертларны җирлекләр бюджетларында карарга.

Статья 9

2016 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен, әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә бүленеп, 37 356,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 10

2016 елга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмнәрен әлеге карарга 13, 14 нче кушымталар нигезендә расларга.

Статья 11

2016 елга Сарман муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 11 397,7 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2016 елга Сарман муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

Статья 12

1. Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2016 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2016 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

Статья 13

Сарман муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны 2016 елда 401 233,5 мең сум күләмендә әлеге карарга 15 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 14

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

Статья 15

Сарман муниципаль районы исеменнән 2015 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә Сарман муниципаль районы бюджетының 2016 елның 1 гыйнварына калган акчалары Сарман муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан тиешле

карар кабул ителгән очракта күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләрен арттыруга 2016 елда җибәрелә.

Статья 16

Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Статья 17

Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Статья 18

Әлеге карарның утәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин